## «Тукайлы яз»

16нчы апрель көнне татар теле һәм әдәбияты атналыгы кысаларында, гимназиябезнең 5нче сыйныф укучылары өчен «Тукайлы яз» интерактив уены үткәрелде. Чара барышында укучылар Тукай эзләре буйлап йөрделәр, әдипнең шигырьләрен ни дәрәҗәдә белүләрен тикшерделәр, әсәрләрен рәсемнәр аша таныдылар. Шулай ук Бөек Җиңүнең 80 еллыгы якынлашкан көннәрдә сугышта катнашкан татар әдипләренә кагылышлы сорауларга җавап эзләделәр.

